| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.04.2025 г.Лениногорск № 239

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы юлларын һәм юл корылмаларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда, ремонтлаганда һәм эксплуатацияләгәндә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыру проектлары һәм схемалары килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 декабрендәге 131-ФЗ номерлы, 2017 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 443-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының юллар һәм юл корылмаларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда, ремонтлаганда һәм эксплуатацияләгәндә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыру проектлары һәм схемалары килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче М.Н. Гирфанов

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72

Расланды

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2025 елның 3 апрелендәге 239 номерлы карары белән

Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары өчен, шул исәптән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының юлларын һәм юл корылмаларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда, ремонтлаганда һәм эксплуатацияләгәндә эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыру проектлары һәм схемалары килештерелергә тиешле оешмалар исемлеге

Россия Эчке эшләр министрлыгының Лениногорск районы буенча юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе бүлеге

---